Чистай муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“1 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе”

| | | |
|---|---|---|
| **Каралган** | **Килешелгән** | **Расланган** |
| ММБ җитәкчесе | /Директор урынбасары | Мәктәп директоры |
| ______/________________./ | ______/Ю.Г.Зайцева/ | __________/Ислямова Н.Н./ |
| МБ утырышы беркетмәсе №1 | беркетмәсе № | Приказ № |
| «    » август 2025 ел. | «    » август 2025 ел | «    » август 2025 ел. |

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Подписано: МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
DN: cn=МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, c=RU, o=МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, email=chis.fbp@tatar.ru
Дата: 2025.09.23 10:26:52 +03'00'

# “Йолдызчык” театр һәм әдәбият түгәрәге

*программасы.*

Программаның үтәлеш вакыты: 2 ел (5-7 сыйныфлар өчен).

Автор: Мөхәммәтҗанова Г Ж. – югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Педагогик киңәшмә

утырышында каралды

Протокол №____

___Август 2025 ел

2024-2026 уку елы.

**Эчтәлек**


1. Аңлатма язуы_______________________________________________3
2. “Йолдызчык” түгәрәгенең  программасы ___________________________5
3. “Йолдызчык” түгәрәге эшен планлаштыру___________________________
4. Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән нәтиҗә_______
5. Әдәбият исемлеге_____________________________________________

# “Йолдызчык” түгәрәгенең

## *программасы*

Төзеде: Чистай муниципаль районы
1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Мөхәмматҗанова Гүзәлия Җавит кызы

### Аңлатма язуы

“Йолдызчык” түгәрәге программасы рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-8 нче сыйныф укучылары белән татар театр сәнгате белән танышу һәм аның төп принципларын өйрәнү теләге белән төзелде. Шулай ук бу программа татар гореф-гадәтләрен, ризыкларын, милли костюмнарның үзенчәлеген, татар рәссамнары, язучылары, шагыйрьләре һәм аларның әсәрләрен өйрәнү һәм аларны сәхнәләштерү  максатын күздә тота.

Программада гади темадан катлаулырак темаларга күчеш эзлекле рәвештә бара.

Балалар белән эш шул рәвештә планлаштырыла: 5-8нче сыйныф укучылары татар халкының мәдәнияте, рухи байлыгы белән таныша; дөрес әдәби телдә аралашырга өйрәнә, татар авторларының кечкенә әсәрләрен укырга, язарга, тәрҗемә итәргә өйрәнә (бу эш балаларга әсәрләрне дөрес аңларга, кабул итәргә булыша), сөйләм теле һәм әдәби тел арасындагы аерманы күрә белергә, тоемларга өйрәнә. Татар мәкальләрен, әйтемнәрен, әкиятләрен уку; туган телләрендә реклама, открытка һәм мини-әкиятләр, әсәрләр, шигырьләр язып карау күздә тотыла. Балалар татар театр сәнгатенең ничек барлыкка килүен өйрәнәләр, театрда уйнаучы актёрлар иҗаты белән танышалар. Сәхнәдә үзләрен иркен тотарга, образга кереп китү күнекмәләрен өйрәнергә, матур сәнгатьне аңлый белергә, аның искиткеч аһәңлелеген тоемларга, хозурланырга,  гади сүзнең көчен, бөеклеген аңларга тырышалар.

Әлеге түгәрәктә укучыларны халкыбызның рухи- әхлакый кануннары белән таныштырырга, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтне үстерергә,мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә дә эш алып барыла.Түгәрәктә танып-белү  эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.

Укытучы алдына куелган бурыч: түгәрәк утырышларын мөмкин кадәр мавыктыргыч, җанлы, кызыклы итеп, төрле алымнар кулланып үткәрүдән тора. Түгәрәктәге дәресләрне очрашу-әңгәмә, виртуаль сәяхәт, экскурсияләр, кичә, театр премьерасы формаларында үткәрергә була.

Әлеге эшчәнлек балаларның күзаллавын киңәйтә, иҗади эш белән шөгыльләнергә, аның ярдәмендә мөстәкыйльлеккә омтылыш, үз халкының теленә һәм тарихына кызыксыну уята. Бәлки, киләчәктә, кайбер укучыларга һөнәр сайларга да этәргеч була алыр.

Шуңа күрә **түгәрәкнең максатын** шулай билгеләдем:

-сүзнең матурлыгын,туган телнең кеше тормышындагы алыштыргысыз ролен укучыларга төшендерү;

-татар әдәбиятының, мәдәниятенең матурлыгын, байлыгын күрергә, сакларга өйрәтү;

-укучыларны әйләнә-тирәлеккә иҗади карарга өйрәтү, аларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

-укучыларда әдәби телгә мәхәббәт тәрбияләү, дөрес сөйләргә, фикерне дөрес, төгәл итеп әйтергә, аңлатырга өйрәтү.

-театр сәнгатенә, актёрлык һөнәренә карата кызыксыну уяту

**Түгәрәкнең бурычлары:**

**-**балаларны иҗатка тарту,иҗади яктан дәртләндерү;

-республикада, шәһәрдә булып узган һәр чараны, театр, концертларны карап барырга, үз фикерләрен булдырырга күнектерү;

-театр сәнгатенең үзенчәлекләрен өйрәтү;

-сәхнәдә үзләрен дөрес тотарга, декламациягә өйрәтү;

-мәктәп, шәһәр чараларында актив катнашу.

**Түгәрәкнең актуальлеге:**

Театр сәнгате бала күңеленә рухи-әхлакый яктан нык тәэсир итә.Актёр ролен үтәүче бала тормышны иҗади яктан аңларга өйрәнә, димәк, сәхнәдә актёр ни өчен шулай сөйләвен, үз-үзен тотышын аңларга тырыша.Аны кешеләр кабул итәме,ни өчен кеше үзенә кызыклы һәм якын булган рольләрне генә башкара. Гомумән, театр-ул тормышның көзгесе. Тормышта булган бөтен уңай һәм тискәре якларны уйнаганда, балалар тормышны яхшырак аңлый.

Театр ул- коллектив, анда укучы башка балалар белән элемтәгә керә, аралаша. Ләкин театрда һәр рольнең үз бурычы бар, димәк һәр бала үзен теге яки бу яктан күрсәтә, сәләтен ача ала, иҗади мөмкинлекләрен үстерә.Театр сәнгате тормышны күзалларга, чагыштырырга, анализларга,планлаштырырга, үз алдына максат куеп, аны чишәргә омтылыш тудыра. Әлеге сәнгать төре балаларда чын мәгънәсендә кызыксыну уята.

**<u>Ел ахырында түгәрәккә йөрүче укучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:</u>**

-Сәнгать төре буларак театрның үзенчәлекләрен, театр сәнгатенең төрләрен, жанрларын белергә;

-башкару сәнгате буларак әсәрләрне матур уку, декламация;

-татар язучыларын, шагыйрьләрен, аларның әсәрләрен белергә;

-татар театр актёрларын танып белергә;

**<u>Булдырырга тиеш гамәлләр :</u>**

-фантазияләү,күзаллау мөмкинлекләрен, сәләтләрен активлаштырырга;

-образга кереп китү өчен вакытны, урынны, ситуацияне дөрес тоемларга;

-биремне үтәгәндә бердәм коллектив белән уңышка ирешергә;

-геройларның холкын дөрес тоемларга, аларны уйнап күрсәтә белергә;

-сәхнәдә үз-үзен тота белергә, сәхнәдәшен тыңлый белергә;

-үзе уйнаган геройга карата үз фикерен булдырырга.

Программаны тормышка ашыру шартлары

Төркемдә укучылар саны: 15 кеше. 5-8нче сыйныф укучылары өчен төзелде.

Программа үтәлеше 1 елга атнасына 2 тапкыр 1әр сәгатьтән саналган.

**Түгәрәк утырышларының төрләре:**

**-**әңгәмә;

-уен;

-әдәби әсәрләр уку һәм аларны анализлау; театр сценарийларын, пьесалар белән танышу;

-спектакль буенча видеоязмалар, аудиоязмалар тыңлау һәм карау;

-иҗади күнегүләр;

-үзлектән мөстәкыйль эш һәм парлап эшләү;

-аңлату;

**Эш формалары**: индивидуаль, парлап, төркемләп, коллектив.

**Нәтиҗә ясау һәм тикшерү формалары**: программаны тиешле рәвештә тормышка ашыру өчен төрле тикшерү формалары кулланыла:

- агымдагы тикшерү-һәр утырышта баланың эшчәнлеген күзәтүдән гыйбарәт;
- арадаш- сыйныфта, мәктәптә үткәрелгән бәйгеләр, бәйрәмнәр, зачёт- дәресләр;
- йомгаклау- ачык чаралар, фестивальләр, театр күрсәтү, концертлар.
  Ел буена һәр баланың иҗади үсешен контрольдә тотуның соңгы нәтиҗәсе-спектакль.

**Белем бирү процессын матди-техник яктан тәэмин итү**

музыкаль фонотека;

аудио һәм видеоязмалар;

театр спектакльләрен булдыру өстендә эшләү өчен кирәкле костюмнар, декорацияләр;

образлар тудыру өчен костюм элементлары;

төшерү һәм чыгышларны анализлау өчен видеокамералар.

“Театрда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре ", «Театр сәнгате төрләре» турында презентация

әкиятләр, пьесалар, балалар китаплары, сценарийлар

Дәресләр өчен иркен, яхшы җилләтелгән сыйныф бүлмәсе яки актлар залы

Аппаратура: музыкаль үзәк, мультимедиа проекторы

Җиһазлар: укытучылар өчен өстәл һәм урындык, укучылар өчен урындыклар.

Программа эчтәлеге

**(136 сәгать. Атнасына 2 сәгать.)**

| Темалар | Бүлекнең максаты һәм бурычлары | Төп эчтәлеге |
|---|---|---|
| **Исәнме, театр (1ч)** | | |
| Тема 1. Кереш дәрес | Балаларны «Театр" төшенчәсе белән таныштыру. Хыяллану, артистларча уйнау теләге тудыру. | Балаларны театр белән таныштыру.Театр төрләре(драма, курчак, комедия) белән таныштыру.Рәсемнәр, иллюстрацияләр карау. |
| **Театр –нур ул! (13 ч)** | | |
| Тема 2. Татар театры тарихы (1-2дәр.) | Театрның тарихы белән таныштыру. Актёр, режиссёр, рәссам, композитор кебек һөнәр ияләренә кызыксыну уяту. Сәхнә, кул чабу, тамашачы кебек сүзләр ярдәмендә сүзлек байлыгын арттыру.Театрның әһәмиятен аңлату. | Укытучы сөйләме,презентация карау, әңгәмә. |
| Тема 3. Театр нигә кирәк? (3-4 дәр.) | | Театр турында әңгәмә, яңа сүзләр белән танышу. Уеннар уйнау. |
| Тема 4.Татар дөньясында беренче театр оешу, беренче "карлыгачлары".(5-6 дәр.) | Беренче театрлар турында мәгълүмат бирү. | Укытучы сөйләме, презентация. |
| Тема 5. Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин – татар театрын оештыручылар. (7-8 дәр.) | Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин турында кыскача мәгълүмат | Укытучы сөйләме, презентация. |
| Тема 6. Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән танышу.(9-10 дәр.) | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән танышу. | Укытучы сөйләме, презентация. |
| Тема 7.Курчак "Әкият" театры белән танышу. (11-12) | Курчак "Әкият" театры белән танышу. | Презентация, укытучы сөйләме. |
| Тема 8. Г.Камалның "Беренче театр" комедиясеннән видеоөзек карау.(13 дәр.) | .Артистларның сәхнәдә үз-үзен тотышына, хәрәкәтләренә, карашына игътибар итәргә өйрәтү.Театр сәнгатенең үзенчәлекләре. | Г.Камалның "Беренче театр" комедиясеннән видеоөзек карау. |
| **Сәхнә осталыгының нигезе.Дикция өстендә эш. (18)** | | |
| Тема 1. Актёрлык осталыгының нигезләре (1-2 дәр.) | Уен аша балаларның тышкы кыяфәтләрен үзгәртергә этәрү (мимика, жест). | Күнегүләр үтәү. «Эмоцияләр"уенын үткәрү. Күнегүләргә бәя бирү, мактау, бер-берсенә ярдәм итү. |
| Тема 2. Кешенең тавыш тембры, сөйләме. Татар авазлары белән эшләү.(3-4 дәр.) | Тиешле образны тудыру өчен хәрәкәт, поза, тавыш интонациясен кулланып үзлектән кирәкле тел чараларын кулланырга омтылыш уяту. Татар авазларын әйтергә , уенда кулланырга өйрәтү. | Сөйләм тембрын, интонациясен үзгәртеп күнегүләр үткәрү. |
| Тема 3.Татар авазлары белән эшләү. (5-6 дәр.)Практика. | Татар авазларын дөрес әйтергә , уенда кулланырга өйрәтү. | Тизәйткечләр кулланып, татар авазларын кабатлау |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 4. Жест, мимика, хәрәкәт.(7-8 дәр.) | Хайваннарның холкын,тормыш рәвешен күрсәтү өчен сыгылмалы хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.Иҗади якын килү, хыялыйлыкны үстерү. | Видеофильмнар карау,балаларның хәрәкәтчәнлеген үстерү. |
| Тема 5. Жест, мимика, хәрәкәт.(9-10 дәр.)Практика. | Төрле ситуациягә карап, мимиканы үзгәртергә, интонация белән уйнарга өйрәтү. | Видеофильмнар карау,балаларның хәрәкәтчәнлеген үстерү.Уеннар уйнау. |
| Тема 6.Сәхнәдәш белән иҗади хезмәттәшлек(10-11 дәр.) | Сәхнәдә үз-үзен тотарга өйрәтү.Бер-беренә карата мөнәсәбәтләрен күрсәтү.Авазлар белән эшләүне дәвам итү. | Сәхнәдә үзләрен тотышларын бәяләү, киңәшләшү, ярдәм итү. |
| Тема 7.Сәхнәдәш белән иҗади хезмәттәшлек (12 дәр.) | Сәхнәдә үз-үзен тотарга өйрәтү.Бер-беренә карата мөнәсәбәтләрен күрсәтү.Авазлар белән эшләүне дәвам итү. | Сәхнәдә үзләрен тотышларын бәяләү, киңәшләшү, ярдәм итү. |
| Тема 8.Сәхнәдә кешеләр белән аралашу.(практика) (13-15 дәр.) | Үз мөмкинлекләреңне бәяли белергә, үзанализ ясарга өйрәнү. | Төрле ситуацияләр аша килешүгә китерүче күнегүләр үткәрү. |
| Тема 9.Үзешчәннәр театрына сәяхәт.(16-18 дәр.) | Иҗатка карата кызыксыну уяту,театр сәнгатен танып-белүне активлаштыру. | Театрда тәртип саклау кагыйдәләрен өйрәнү. |
| **Театр һәм актер. (6 сәг.)** | | |
| Тема 1.Татарстан театрлары белән таныштыру.(1 дәр.) | Татарстанның төрле шәһәрләрендә урнашкан театрлар белән танышу. Г. Камал исемендәге драма һәм комедия театры, К. Тинчурин театры һ.б. | Видеоязмалар,иллюстрацияләр күрсәтү. |
| Тема 2. Татарстан театрлары белән таныштыру.(2 дәр) | Яшь тамашачылар театры, Курчак театры белән танышу | Видеоязмалар, презентацияләр күрсәтү. Әңгәмә. |
| Тема3. Театр артистлары.(3-4 дәр). | Шәүкәт Биктимеров, Рәшит Шамкай, Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Рөстәм Гайзуллин кебек легендар һәм яшь артистлар белән танышу | Артистлар катнашында спектакльләрдән өзекләр карау. |
| Тема 4. Актер һөнәренең үзенчәлекләре.(5-6 дәр.) | Актерлык һөнәренең үзенчәлекләрен барлау, оста булуның серләренә төшенү. | Әңгәмә, аралашу, фикер алышу. |
| **Театр эшчәнлеге. (25 ч)** | | |
| Тема 1. Сүзсез хәрәкәтләр белән эмоцияләрне аңлата белү(1-2 дәр.) | Игътибарлылык, күзаллау, хыялыйлык хисе тәрбияләү. Импровизация,артистлылык аша матурлыкка омтылыш тәрбияләү.Гәүдә сыгылмалылыгы белән хисләрне белдерергә өйрәтү. | “Сын”, “Реклама” уеннары уйнау. |
| Тема 2. Әсәрне сайлау , аның белән җентекләп танышу.(3-4 дәр.) | Әсәрне сәнгатьле уку, укылган өлешләрне күзаллау, балаларның бер-берсенә ярдәмләшүен тәэмин итү. | Әсәрнең аерым өлешләрен уйнап карау. |
| Тема 3. Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку(5-6 дәр.). | Диалог вакытында мимика һәм хәрәкәт өстендә эшләү. Дикциягә әһәмият бирү. | Төгәл дикцияне, интонацияне үстерүгә юнәлтелгән уеннар уйнау. |
| Тема 4. Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, нигыту буенча репетиция. (7-8 дәр.) | Балаларны әсәрдәге персонажлар белән таныштыру, аларның характерлары, гадәтләре турында сөйләшү, аерым өлешләрен сәхнәдә уйнау. | Әсәрнең өлешләрен уйнау, кушып спектакль дәрәҗәсенә китерү. |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 5. Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, ныгыту буенча репетиция. (9-10 дәр.)Практика. | Балаларны әсәрдәге персонажлар белән таныштыру, аларның характерлары, гадәтләре турында сөйләшү, аерым өлешләрен сәхнәдә уйнау. | Әсәрнең өлешләрен уйнау, кушып спектакль дәрәҗәсенә китерү. |
| Тема 6. Сөйләм техникасы буенча эш.(11-12 дәр.) | Укучыларның коммуникатив, ритмик, музыкаль сәләтләрен үстерү өстендә эш. | Образ тудыру һәм сәхнә тиралегeн дөрес файдаланырга өйрәтү. |
| Тема 7. Хәрәкәт техникасы өстендә эш.(13-14 дәр.) | Образ тудыру һәм сәхнә тирәлегeн дөрес файдаланырга өйрәтү. | Төрле рольләргә караган хәрәкәтләрне күрсәтү, кабатлау, өйрәнү. |
| Тема 8. Спектакльгә әзерлек. (практика)(15-16 дәр.) | Балаларны декорацияләр куярга, сәхнәне бизәргә өйрәтү.Спектакль уңышлы үтәчәгенә ышаныч тәрбияләү. | Сәхнә әзерләү. Авыр очракларда киңәшләр бирү. |
| Тема 9. Спектакль буенча репетиция. (практика)(17-18 дәр.) | Балаларны спектакльне тояргa,чыгыш алдыннын тәртип сакларга өйрәтү. Бердәмлек, ярдәмчеллек тәрбияләү. | Репетиция барышында сөйләм, хәрәкәт техникасына,персонажларның бер-берсе белән дөрес аралашуына игътибар итү. |
| Тема 10. Афишалар әзерләү.(19-20 дәр.) | Афишаларны дөрес, зәвыклы итеп ясарга өйрәтү. Ата-аналарны да бу эшкә җәлеп итү. | Афиша үрнәкләрен күрсәтү. |
| Тема 11. Афишалар әзерләү.(21-22 дәр.) | Афишаларны дөрес, зәвыклы итеп ясарга өйрәтү. Ата-аналарны да бу эшкә җәлеп итү. | Афиша үрнәкләрен күрсәтү. |
| Тема 12. Спектакль буенча генераль репетиция ясау. (23 дәр.) | Сәхнәдә рольгә кереп китү, әйләнә-тирәдә дөрес хәрәкәт итү, ситуациягә карап импровизациягә әзер булу күнекмәләрен ныгыту. | Сәхнәдә репетиция ясау. |
| Тема 13. Практик эш: куелачак спектакльне репетиция видеоязмаларыннан карау. (24 дәр.) | Тамаша вакытында тәртип кагыйдәләрен кабатлау, зәвыклылык формалаштыру. | Спектакльне карау. |
| Тема 14.Спектакль буенча фикер алышу.(25 дәр.) | Спектакльне әзерләү этапларын аңларга өйрәтү,такт хисе һәм рухи үзенчәлек тәрбияләү. | Спектакль буенча фикер алышу. |
| **Башлангыч сыйныфлар өчен спектакль күрсәтү. (2 ч)** | | |
| **Халык авыз иҗаты (14сәг.)** | | |
| Тема 1. Мәкальләр белән танышу.(1-2 дәр.) | Халык мәкальләрен укып, мәгънәсен аңларга өйрәтү. Халыкның бай мирасына сакчыл караш тәрбияләү. | Әдәп, акыл, тел турында мәкальләр өйрәнү. |
| Тема 2.Әйтемнәр белән танышу.(3 дәр.) | Әйтемнәрдә халыкның акылы, күзәтүчәнлеге, игътибарлылыгы чагылышын күрсәтү. | Әйтемнәр уку,истә калдыру буенча уеннар уйнау. |
| Тема 3.Тизәйткечләр белән танышу.(4-5дәр.) | Тел байлыгын үстерү, сөйләм телен баету, тел чарлау. | Тизәйткечләр уку буенча ярышлар , уеннар үткәрү. |
| Тема 4.Бишек җырлары, такмаклар белән танышу. (6-7 дәр.) | Халык моңын тыңларга, такмакларын өйрәнергә омтылыш уяту. | Бишек җырлары, такмаклар уку, тыңлау, җырлау. |
| Тема 5.Әкиятләр белән танышу. (8-9 дәр.) | Әкиятләрнең тәрбияви максатын аңлау, хыял, күзаллау кебек хисләрне үстерү. | Әкиятләр уку, видеоязмалар карау. |
| Тема 6. Халык уеннары белән танышу.( 10-11 дәр.) | Уеннар аша игътибарлылык, зирәклек, дөрес хәрәкәтләнү, | Халык уеннары уйнау. |

| | | |
|---|---|---|
| | оешканлык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | |
| Тема 7. Милли бәйрәмнәр. (12-13 дәр.) | Сабантуй, Карга боткасы, Нәүрүз кебек милли бәйрәмнәр, йолалар белән танышу. | Видеоязмалар карау, күргән йолалар турында әңгәмә, уеннар. |
| Тема 8. Мини-сабантуй үткәрү. (практика). (14 дәр.) | Укучыларның тизлеген, зирәклеген, илтифатлылыгын үстерә торган уеннар, ярышлар үткәрү. Татар милли уеннарына кызыксыну уяту. | Уеннарда, ярыш-бәйгеләрдә катнашу.Канәгатьлелек хисе тәрбияләү. |
| **Татар халкының милли костюмнары, ашлары(12 сәг.)** | | |
| Тема 1.Татар милли киемнәре. Ирләр киеме. (1-2 дәр.) | Татар милли ирләр киемнәренә кызыксыну уяту, аларның җайлылыгына, хәрәкәткә комачауламавына игътибар итү. Камзул, читек, билбау сүзләре белән танышу. | Ирләр өчен милли киемнәрне тотып, киеп карау. |
| Тема 2.  Хатын-кызлар киеме.(3-4 дәр.) | Хатын-кыз милли киеменә кызыксыну уяту.Калфак , читек, бала итәкле күлмәк кебек яңа сүзләрне бала сөйләменә кертү.Киемнәрнең ачык төстә булуына игьтибар итү. | Хатын –кызлар өчен милли киемнәрне тотып, киеп карау. |
| Тема 4.Бизәнү әйберләре.(5-6 дәр.) | Татар халкының бизәнү әйберләре белән таныштыру.Зәвыклылык. матурлыкка омтылыш тәрбияләү.Алка, чулпы, күкрәкчә кебек яңа сүзләрне сөйләмгә кертү. | Иллюстрацияләр, рәсемнәр, презентация карау. |
| Тема 5.Милли ашлар.(7 дәр) | Чәк-чәк, кабартма, кош теле , гөбәдия, коймак  кебек татлы ризыклар белән танышу. Дирбиясе белән танышу. | Иллюстрацияләр, видео карау |
| Тема 6. Милли ашлар (8 дәр) | Өчпочмак, вак бәлеш, итле бәлеш кебек итле милли ашлар белән танышу, дирбиясен өйрәнү. | Иллюстрацияләр, видео карау |
| Тема 7.Практик эш. Милли ашлар пешерү.(9-10 дәр.) | Технология бүлмәсендә  гади милли ашларын (коймак, өчпочмак)пешереп карау. Әниләре белән өйдә әзерләнгән ризык алып килү... | Ашларны пешереп карау, әңгәмә, ярдәмчеллек тәрбияләү. Чәй эчү. |
| Тема8.Җырлы –биюле кичә үткәрү.(11 дәр.) | Милли кимнәр киеп милли уеннар уйнау, такмаклар башкару,татар биюенең серләренә төшенү. | Җырлы, биюле уеннар уйнау, ярдәмчеллек, бердәмлек тәрбияләү. |
| *Тема 9. Үзлектән эш: Татар халкының милли костюмнары, ашлары(12 дәр.)* | Милли костюмнар, ашларны белү, истә калдыру максатыннан әзерләнгән сорауларга җавап бирү.Татар милли орнаменты белән костюмнарны бизәү. Милли ашлар, киемнәр белән, татар халкының рухи байлыгы белән горурлану хисе тәрбияләү. Һәр эшкә иҗади якын килү теләген уяту. | Рәсем ясау, сорауларга җавап бирү. |
| **Татар язучылары, шагыйрьләре белән танышу(14сәг.)** | | |
| Тема 1.Г. Тукай-бөек шагыйрь.(1-2-3 дәр.) | Г. Тукайның шигырьләре, әкиятләре белән танышу. Олылар өчен дә шигырьләр язуын искәртү.Кечкенә әсәрләрен сәхнәдә уйнап карау. Бөек шагыйрьнең шигырьләрен укырга, теләк тудыру. | Бөек шагыйрьнең шигырьләрен уку., ятлау |
| Тема 2. Ш. Галиев шигырьләре белән танышу. | Ш. Галиев шигырьләре белән танышу.Шигъри әсәрләрне укырга | Ш. Галиев әсәрләрен уку. |

| | | |
|---|---|---|
| (4-5-6 дәр.) | омтылыш уяту. | |
| Тема 3. Ф. Яруллин әсәрләре күңелгә якын. (7-8-9 дәр.) | Ф. Яруллин иҗаты белән танышу.Әкиятләренең тәрбияви максатны күздә тотуын, шигырьләренең тирән мәгънәле булуын укучыларга җиткерү. | Ф. Яруллин әсәрләрен сәнгатьле уку. |
| Тема 4. Роберт Миңнуллин- балалар шагыйре дә.(10-11-12 дәр.) | Р. Миңнуллин иҗаты белән танышу. Кечкенәләр өчен язылган шигырьләренең максатчанлыгын, кызыклы, мавыктыргыч булуына игътибар итү. | Р. Миңнуллин шигырьләрен уку. |
| Тема 5. Шигырь бәйрәме.(13 дәр.) | Алда өйрәнгән авторларның шигырьләрен, әкиятләрен сәнгатьле итеп уку. | Шигырьләр уку, бүләкләү. |
| **Сәхнә илһам китерә. (17 сәг.)** | | |
| Тема 1. Ф. Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен уку, җентекләп танышу(1дәр.) | Әсәрне сәнгатьле уку, укылган өлешләрне күзаллау, Балаларның бер-берсенә ярдәмләшүен тәэмин итү. | Әсәрнең аерым өлешләрен уйнап карау. |
| Тема 2. Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку.(2-3 дәр.) | Диалог вакытында мимика һәм хәрәкәт өстендә эшләү. Дикциягә әһәмият бирү. | Төгәл дикцияне, интонацияне үстерүгә юнәлтелгән уеннар уйнау. |
| Тема 3. Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, ныгыту буенча репетиция.(3-4-5 дәр.) | Балаларны әсәрдәге персонажлар белән таныштыру, аларның характерлары, гадәтләре турында сөйләшү, аерым өлешләрен сәхнәдә уйнау. | Әсәрнең өлешләрен уйнау, кушып спектакль дәрәҗәсенә китерү. |
| Тема 4. Сөйләм техникасы буенча эш.(6-7 дәр) | Укучыларның коммуникатив, ритмик, музыкаль сәләтләрен үстерү өстендә эш. | Образ тудыру йәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. |
| Тема 5. Хәрәкәт техникасы өстендә эш.(8 дәр.) | Образ тудыру һәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. | Төрле рольләргә караган хәрәкәтләрне күрсәтү, кабатлау, өйрәнү. |
| Тема 6. Спектакльгә әзерлек.(9-10 дәр.) | Балаларны декорацияләр куярга, сәхнәне бизәргә өйрәтү.Спектакльуңышлы үтәчәгенә ышаныч тәрбияләү. | Сәхнә әзерләү. Авыр очракларда киңәшләр бирү. |
| Тема 7  Спектакль буенча репетиция.(11-12-13 дәр.) | Балаларны спектакльне тоярга,чыгыш алдыннын тәртип сакларга өйрәтү. Бердәмлек, ярдәмчеллек тәрбияләү. | Репетиция барышында сөйләм, хәрәкәт техникасына,персонажларның бер-берсе белән дөрес аралашуына игътибар итү. |
| Тема 8. Афишалар әзерләү. 14-15 дәр.) | Афишаларны дөрес, зәвыклы итеп ясарга өйрәтү. Ата-аналарны да бу эшкә җәлеп итү. | Афиша үрнәкләрен күрсәтү.Авырсынган очракларда киңәш бирү. |
| Тема 9. Спектакль буенча генераль репетиция ясау.(практика)(16-17 дәр.) | Сәхнәдә рольгә кереп китү, әйләнә-тирәдә дөрес хәрәкәт итү, ситуациягә карап импровизациягә әзер булу күнекмәләрен ныгыту. | Сәхнәдә (костюмнар киеп, декорацияләр белән) репетиция ясау. |
| **Спектакльне ата-аналарга, укытучыларга, мәктәп балаларына күрсәтү.(2 сәг.)** | | |
| **Хәтер китабы (5 сәг.)** | | |
| Тема 1.Тирә-якны өйрәнү музеена сәяхәт.( 1 дәр.) | Туган якның тарихы белән танышу. Музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истә тоту.Игътибарлылык, | Музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истә тоту.Экспонатлар белән |

| | | |
|---|---|---|
| | кызыксыну хисе тәрбияләү. | танышу. |
| Тема 2. “Хәзинә” паркындагы милли байлык. (2 дәр.) | Чистай шәһәре һәм районында туып-үскән, иҗат иткән язучы-шагыйрьләребезнең сыннары янында шигырьләр, әсәрләреннән өзекләр уку,тормыш юлы белән танышу. | “ Хәзинә” паркы буенча сәяхәт. |
| Тема 3.Казан музейларына виртуаль сәяхәт.(3-4-5 дәр.) | Казан музейларына карата кызыксыну уяту, анда булу, экспонатларны чынлыкта күрү теләге уяту. | Видеоязмалар, иллюстрацияләр карау. |
| **Алга, һәрвакыт алга! (5 сәг.)** | | |
| Тема 1-4. Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу.(1-2-3-4 -5дәр.) | Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу өчен нигезләмәләр белән танышу.Катнашучыны билгеләү. Репетицияләр ясау. | Репетицияләр ясау, костюмнар, декорацияләр әзерләү, бер-берсенә булышу, киңәш бирү теләге тәрбияләү. |
| **Йомгаклау. (2 сәг.)** | | |
| Тема 1-2. Түгәрәкнең эшен тәмамлавы. Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. (1-2 дәр.) | Укучыларны сәхнәдә иркен тотарга , уеннарда актив катнашырга, дөрес сөйләм күнекмәләрен истә тотарга , үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен үтәргә тәкъдим итү. | Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. |

**Укыту-тематик план**

| № п/п | Бүлекләрнең исеме | Укыту елы | Сәгать саны | | | | Тикшерү формасы. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бар лыгы | Дәрес ләр | Экскурси яләр, практика | Үзлектән эшләр. | |
| 1. | Исәнме, театр. | 1 | 1 | 1 | | | рәсем |
| 2. | Театр –нур ул! | 1 | 13 | 13 | | | |
| 3. | Сәхнә осталыгының нигезе.Дикция өстендә эш | 1 | 18 | 15 | 3 | | жест, мимика, дикциягә каралган күнегүләр |
| 4. | Театр һәм актер. | 1 | 6 | 6 | | | “Без артист булачакбыз!” темасына рәсемнәр. |
| 5. | Театр эшчәнлеге | 1 | 25 | 21 | 4 | | Импровизация |
| 6. | Башлангыч сыйныфлар өчен спектакль | 1 | 2 | | 2 | | Рольләрне башкару |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтү | | | | | | |
| 7. | Халык авыз иҗаты | 1 | 14 | 13 | 1 | | Тизәйткечләр, әйтемнәр, мәкальләр уку. |
| 8. | Татар халкының милли костюмнары, ашлары | 1 | 12 | 10 | 1 | 1 | Ризык пешерү.Костюмга бизәк ясау. |
| 9. | Татар язучылары, шагыйрьләре белән танышу | 1 | 14 | 14 | | | Шигырьләр уку. |
| 10. | Сәхнә илһам китерә. | 1 | 17 | 16 | 1 | | Күнегүләр үтәү, репетиция |
| 11. | Спектакльне ата-аналарга, укытучыларга, мәктәп балаларына күрсәтү | 1 | 2 | 2 | | | Премьера |
| 12. | Хәтер китабы | 1 | 5 | 4 | | 1 | Әңгәмә. |
| 13. | Алга, һәрвакыт алга! | 1 | 5 | 3 | 2 | | Бәйгеләрдә чыгышлар |
| 14. | Йомгаклау. | 1 | 2 | 2 | | | Анкета |
| **Барлыгы:** | | | **136** | **120** | **14** | **2** | |

## Кулланылган әдәбият исемлеге.

1. Хәйдәрова Р. З. , Баһавиев И.И.,Басыйрова Г.З. “Мәктәптә бәйрәмнәр, кичәләр”.-Казан:1999.
2.  Казыйханов.В. “Әхлак дәресләре”.-Яр Чаллы: 2001.
3.  Зарипов З. М., Хәмитов И. М. “ Бар ямьнәр дөньяларда” җыентыгы. -Яр Чаллы.: 2003.
4. Максимов Н.В., Шәйхразиева З. В. Башваткычлар, уеннар, тестлар.-К. “Мәгариф” нәшрияты:2010.

5.Халикова Р.Ш. “Раушан көзге”.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты: 1993.
6.Интернет сайт: magarif@bk/ru

7.Шәмсетдинов Г.А. “Хәерле көн, укытучы”. Мөгаллимнәргә, методистларга, тәрбиячеләргә методик кулланма._Казан: “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексы, 2004.
8. Колчеев Ю.В., Колчеева Н.И. «Театрализованные игры в школе». – М.: 2001 г.
9. Чурилова Э.Т. «Методика организации театральной деятельности дошкольников и мл. школьников» -М.: 2001г.
10. .«Театр, где играют дети». Учебно-методическое пособие для руководителей детских театральных коллективов. Под редакцией А.Б.Никитиной. М.: Владос, 2001.

КАЛЕНДАРЬ – ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1. | Тема 1. Кереш дәрес | 1 сәг. | | | |
| 2. | Тема 2.. Татар театры тарихы (1-2дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 3. | Тема 2. Театр нигә кирәк? (3-4 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 4. | Тема 4.Татар дөньясында беренче театр оешу, беренче “карлыгачлары”.(5-6 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 5. | Тема 5. Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин – татар театрын оештыручылар. (7-8 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 6. | Тема 6. Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән танышу.(9-10 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 7. | Тема 7.Курчак “Әкият” театры белән танышу. (11-12) | 2 сәг. | | | |
| 8. | Тема 8. Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән видеоөзек карау.(13 дәр.) | 1 сәг. | | | |
| 9. | Тема 1. Актёрлык осталыгының нигезләре (1-2 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 10. | Тема 2. Кешенең тавыш тембры, сөйләме. Татар авазлары белән эшләү.(3-4 дәр.) | 2 сәг. | | | |
| 11. | Тема 3.Татар авазлары белән эшләү. (5-6 дәр.)Практика. | 2 сәг. | | | |
